

# ГӘРӘБӘ

## Әдәби берләшмә газетасы

Әйсин,телем,туган телем,тамыр телем

Җир астыннан тарих табар телем..

Әй син,телем,рәхәт телем,авыр телем.

(Л.Шагыйрьҗан)

№1-2




## *Казан Педагогия көллиятенә 140 ел...*

Казан педагогия көллияте үзенең 140 еллык юбилеен бәйрәм итте. Юбилей уңаеннан оештырылучы чарада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары-мәгариф һәм фән министры Энгель Фаттахов катнашты.

*Дәвамы 2 биттә →*

***Рубрикалар:***

- ***Бөек шәхес***
- ***Кызыклы вакыйгалар***
- ***Иҗат***
- ***Халык иҗаты***
- ***Хуҗабикә***
- ***Уңган куллар***
- ***Башваткыч***

Казан Педагогия көллиятенә 140 ел...

*Дәвамы*










**1876 нчы елда Казан татар укытучылар мәктәбенә нигез салынган.**

**XX гасыр барышында уку йортының атамасы күп мәртәбә үзгәрә:**

**1921 нче елдан - Казан татар педагогика техникумы;**

**1937 нче елдан - Казан педагогика училищесы;**

**1939 нчы елдан - читтән торып уку педагогика училищесы;**

**1961 нче елдан - Казан педагогика училищесы;**

**1995 нче елны Казан педагогика училищесы Казан педагогия көллиятенә әверелде.**

**2014 нче елның сентябрендә Казан педагогия көллияте базасында Татарстан Республикасы педагогик кадралар әзерләү Ресурс үзәге ачылды.**

**Көллияттә төп һөнәри укыту программалары буенча эшчәнлек бара: *"Мәктәпкәчә белем бирү"*, *"Башлангыч сыйныфларда белем бирү"*, *"Адаптив физик культура"*, *"Гамәли информатика"*.**



*Тәрәбә*

# Каюм Насыйри

Бөек шәхес



1825 елның 14нче февралендә элеккеге Казан губернасының Зөя өязе Югары Шырдан авылында дөньяга килгән К. Насыйри, үз чоры өчен укымышлылыгы ягыннан иң югары баскычка күтәрелеп, татарлар арасында иң беренчеләрдән булып энциклопедик галим дәрәҗәсенә ирешә.

Каюм Насыйриның бабалары һәм атасы үз заманының шактый укымышлы, танылган кешеләре булалар. Башлангыч белемне ул атасыннан ала. 1841 елда Каюмны Казандагы бер мәдрәсәгә укырга бирәләр. 1855 елга кадәр ул мәдрәсәдә укып, гарәп-фарсы телләрен өйрәнү өстенә, үзлегеннән татар телен дә яхшы үзләштерә. Яшерен рәвештә русча да укый.

1855 елда Насыйрины Духовное училище дип аталган рус мәктәбенә татар теле укытучысы итеп чакыралар. Насыйриның беренче практик эше — укытучылык хезмәте шунда башлана. Соңыннан ул Духовная семинариядә татар теле укытучысы булып эшли. Анда укытучылар белән таныша, алар белән якыннан аралаша, алардан рус телен һәм башка фәннәрне тырышып өйрәнүен дәвам итә. Аннары ул, Казан университетына ирекле тыңлаучы булып йөреп, югары белем ала. Каюм Насыйри татар балаларына рус теле укытуга зур игътибар бирә. Аның семинариядә укыту эше 1870 елга кадәр дәвам итә.

1871 елны Насыйри, семинариядә эшләүдән туктап, татар балаларына рус теле укытуга ныклап керешә. Насыйрига бу эшне алып бару җиңел булмый. Укыту өчен урын - квартира табарга, балаларны укуга тарту буенча күп тырышлыклар күрсәтергә, төрле җәфалар чигәргә туры килә. Шул рәвешчә, реакцион көчләрнең каршы килүләренә карамастан, бик авыр шартларда, зур газаплар күреп, Насыйри татар балаларына рус теле өйрәтү юлында, беренче буларак, зур тырышлыклар күрсәтә. 1876 елда Насыйри, мәктәпләр инспекторы Радлов белән икесе арасында чыккан каршылык аркасында, бу русча-татарча башлангыч белем бирү мәктәбендә укытучылык эшеннән туктый. К. Насыйриның укытучы хезмәте моның белән генә чикләнми.

Ул тагын ике-өч ел Яңа бистәдә рус-татар мәктәбендә эшли.

1879 елдан башлап, Насыйри калган гомерен, рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итмәстән, тик язучылык эшенә һәм фән хезмәтенә генә багышлый. Аның иң яхшы әсәрләре шушы вакытларда языла. Ул барлык көчен китап һәм дәреслекләр язуга бирә, кулына төшкән акчасын аларны бастыруга тота. Татар халкын төрле фән нигезләре белән иң беренче таныштыручы кеше дә К. Насыйри була. Аның тарафыннан математика, география, ботаника буенча дәреслекләр төзеп чыгарыла. К. Насыйри – тел белемен үстерүгә искиткеч зур өлеш керткән галим. Ул сүзлекләр төзи. Математика, география, табигать фәннәре буенча татарча терминнар сүзлеге – безгә олуг галим калдырган мирас. Татар теленең беренче фәнни грамматикасы да аның хезмәте.

Ярты гасыр буена түземле һәм нәтиҗәле иҗат итеп, тел, әдәбият, халык авыз иҗаты, педагогика һәм башка бик күп төрле фәннәр (география, математика, табигать һ. б.) өлкәсендә 40 тан артык әсәр биргән галим-мәгърифәтче, педагог һәм язучы Каюм Насыйри бөтен тормышын, әдәби талантын халыкка хезмәт итүгә багышлады, татар халкының аң-белемен күтәрү, агарту юлында гаять әһәмиятле эшләр башкарды.

К. Насыйриның әдәби иҗат эшчәнлеге дә күпкырлы. Анын күпсанлы тәрҗемәләре, үз язмалары, фольклор материаллары әдәбиятыбызның кыйммәтле хәзинәләре. Халкыбызның гореф-гадәтләре, этнографиясе, тарихы да галим игътибарыннан читтә калмаган. Әдип һәм галимнең медицина, музыка, җыр сәнгате буенча әйткән фикерләре дә татар тарихын өйрәнүчеләрдә зур кызыксыну уята. 1925 елда безнең педагогия көллиятебезгә Каюм Насыйри исеме бирелгән була.

Профессор Н.К. Дмитриев әйткәнчә "үз халкының һәм үз чорының улы булган" К. Насыйрины халкыбыз бүген дә олылый. Аның туган ягында һәм башкалабыз Казанда музейлар эшли. Мәгариф алдынгыларына бөек педагог исемендәге премияләр бирелә, шагыйрь һәм язучыларыбыз аңа багышлап яңадан-яңа әсәрләр иҗат итәләр.

*Кәримова Фәридә, 212 группа*







“Әй угыл, гакыллы балага атлаган саен гыйбрәтләр бар, вәгазьләр бар, мәгърифәт хасил итә күр.”

“Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел. Бүтән телләрдән бер дә ким түгел, эшләмәгәнлек сәбәпле генә ул шулай артта калган.”

*Каюм Насыйри*

# Кыш-…

Кызыклы вакыйгалар



Кыш – иң могҗизалы ел фасылы. Ул дөньга аклык, пакьлык, чисталык алып килә. Күңелләр ниндидер бер могҗиза белән тула. Кешеләр кышның төп бәйрәмен – Яңа елны көтәләр.

Яңа ел – ул яңа өметләр, яңа тормыш. Кешелек гомерендә яңа битләр ачыла. Узып китүче иске елда эшләнмәгән эшләргә, булган хаталарны төзәтергә, ирешмәгән максатларга янәдән мөмкинлек бирелә.

Яңа ел – нинди гаҗәеп вакыт! Һәр кеше күңеле гади булмаган ниндидер хис белән урала. Балалар, олылар- барысы да могҗиза көтә.

Яңа ел – ул тылсымлы мизгел. Җаннарга шатлык, йортларга куаныч кергән вакыт. Шушы сихри төндә һәркем хыялларының чынга ашуына чын күңелдән ышана. Һәр гаиләдә изге теләкләр яңгырый: киләсе яңа ел да бәхет, шатлык, исәнлек, саулык, байлык алып килсен иде…

*Гибадуллина Миләүшә,212 төркем*

Гәрәбә



***Иҗат*** - гүзәл гамь ул, иң югары дәрәҗәдәге изге тынгысызлык ул. Иҗат ике канатлы ул: яхшыны исбат итү, яманны инкар итү ул, яхшылыкка мәхәббәт, яманлыкка нәфрәт ул!

*Хәсән Туфан*

## Әти-әнинең кадерен белү

N ... шәһәренең бер урамында яшәгән ди хатын белән ир. Аларның ике малае булган. Берсенең исеме – Самат, ә икенчесенең – Азат. Кечкенә  чакта алар бик акыллы , тәртипле булып үскәннәр,  әти-әниләренә кире сүз әйтмәгәннәр. Иртән үк алар көтүгә киткәннәр һәм  көне буе саф һава сулаганнар. Вакытлары булган чагында малайлар күп китап укыганнар. Аларның үсеп җиткәч, галим буласылар килә иде. Бу хыял белән алар иртән уяндылар кич белән йокладылар. Хатын белән ир көне-төне эшләгәннәр. Самат белән Азат аларны бик аз күргәннәр...

Күп еллар узгач, Самат белән Азат үзгәрәләр, аларның әти-әниләре белән дә мөнәсәбәтләре начарая. Самат чын егеткә әйләнә, матурая, белемле кеше була. Ә менә Азат начар якка үзгәрә. Ул мәктәпне дә тәмамлый алмыйча  кала, әнисе белән һаман  бәхәсләшә, аңа гел  кире сүз әйтә. Әнисе  Азатны  төннәрен йокламыйча көтеп утыра иде. Кызганычка каршы,  егет аны аңламаган.

Көннәрдән бер көнне Азат төнлә кайтып, киемнәрен җыя башлый һәм әнисенә мондый сүзләр әйтә: “Мин чыгып китәм, сездән  арыдым, бүтән кайтмыйм. Сез мине аңламыйсыз,  һаман акыл өйрәтәсез, ә үзегезнең акылыгыз минекеннән күбрәк түгел! Мин яңа дуслар таптым, алар мине бүтәнчә яшәргә өйрәттеләр. Анда  бик рәхәт. Кешеләр үз законнары белән яшиләр. Бүтән кешегә начарлык китерү турында уйларга ярамый. Бары тик үз тормышың гына

кызыксындыра ала ... Мине эзләп йөрисе булмагыз! Хуш, сау бул ! Синең белән вакыт әрәм итәм", - дип егет киемнәр сумкасын ала да, каядыр чыгып китә.

Әнисе сүз әйтә алмыйча, бүлмәнең уртасында басып кала. Аның зәңгәр күзләре яшькә тулып, хәтта аларны ача алмый иде. Нинди хисләр кичергәндер бу хатын-кыз... Аларны сүзләр белән язып бетереп булмый. Үз акылына килгәч, ул Саматка шалтырата башлады. Соңгы вакытларда ул әти-әнисенә килми, шалтыратмый башлады. Аның яңа тормышы башланды. Әнисе аңа шалтыраткач, ул гаҗәпләнде. Азат турында сорагач, Самат аптыраашта калды. Егет ишеткәнем һәм сөйләшкәнем юк дип әйткәч, әнисе үкси-үкси елый башлады. Самат әнисен юатырга тырышып карады, тик аның файдасы тимәде. Хатын-кыз кайгыдан авыруга сабышты. Ул бернәрсә дә ашамый, эчми башлады. Ире сорау биргәндә җавап бирми, бер кешене дә тыңларга теләми, үз уйларына баткан. Аны бернәрсә дә кызыксындырмаган. Әтисе Саматка шалтыратып, чакырмакчы булган, тик ул вакыт юк дип, тиз генә трубканы куйган.

Әниләре бер-ике айдан соң кешеләрне күрми, ишетми, танымый башлый. Ул бары тик улларының исемнәрен әйтә иде: "Азат, Самат, кайда сез? Әниегез сезне сагына". Ир-ат хатынына карап, үзе дә авыруга сабыша башлаган.

Бер көнне аны телевизор караганда, кинәт йокы баса башлады. Телевизорны сүндермичә, ул тизрәк ятарга ашыкты. Шул вакытта телевизорга ялганган шнур кинәт яна башлады. Ут бөтен өйне чолгап алды. Ир белән хатын тирән йокыга чумып, аның исен дә сизмичә тәтенгә тончыкты. Күршеләр янгынны күреп, су ташый башладылар, тик бу вакытта өй янып беткән иде инде.

Бу фаҗиганы белгәч, Самат өенә ашыкты. Ул үткән тормышы турында уйлана башлады. Балачакта булган күңелле мизгелләрне исенә төшергәч, аның йөрәгенә җылылык кергән кебек тоелды. Өй янына барып җиткәч, янып беткән ишек алды аның бөтен кәефен бетерде, күз яшьләре акты. Шул мизгелдә аның башында беруй гына иде: "Вакытымны әрәм иттем. Бәхетемне эзләп йөргәндә, алар минем ярдәмемә мохтаҗлыкта яшәгәннәр.Теге вакытта әнием шалтыраткан иде бит, ә мин аны кире кактым , тыңлый алмадым . Ихтимал , ул миңа берәр әйбер сөйләргә теләгәндер... Нигә мин аны тыңламадым соң? Нигә Азатны эзләшергә булышмадым икән? Бу сораулар аның башын авырттыра башладылар. Шул вакытта ул әти-әнисенең иң кадерле кешеләр булганын аңлады. Ул уйланып торганда, Азат дуслары белән көлешеп үтеп бардылар. Азат хәтта әйләнеп тә карамады ...

*Мәрдәнова Айгөл , 212 төркем*

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*

Шигырьләр

Иҗат



Кайтмакчы булып , яна йөрәк,
Әйтерсең лә, күңел сагы.
Йөрәкләрдә булган кайнар уйлар
Әллә ничек өйгә ашкына.

Дуслар белән бергә йөргән юллар
Искә төшә һәрбер көнемдә.
Ул юлларда кайтып барган чакта,
Әрнеп китә йөрәк түрендә.

Кайтам инде, кайтам бик сирәк,
Туган авылым, синең янына.
Кайчан кире кайтырмын дип,
Китәм тагын ерак юлларга.

*Исхакова Ләйсән , 212 төркем*



Тәрәбә

Шигырьләр

Халык иҗаты

Әни кирәк бала өчен, әни кирәк,
Кочагына алып назлар өчен.
Гаепләрең булган чакларда да,
Синең күңелеңне аңлар өчен.

Әти кирәк бала өчен, әти кирәк,
Авырлыкта сине яклар өчен,
Бер карашы, сүзе, эше белән,
Ялгыш адымнардан саклар өчен.

Әни кирәк бала өчен,әни кирәк,
Сабырлыкны анда күрер өчен.
Әни булган чакның рәхәтләрен,
Бәхетләрен мәңге белер өчен.

Әти кирәк бала өчен, Әни кирәк,
Адымнарың җиңел булсын өчен.
Төнең тыныч, киләчәктә таңнар
Гел кояшлы булып тусын өчен.

*АЛСИНӘ С.*

Бигрәк матур инде кышлар бездә -
Казан урамнары ап-ак булган.
Мин киләмен, куркып кына
басып,
Ак келәмнән, энҗе белән тулган.

Буярмын да, юкка чыгар сыман
Ак хисләргә таплар тиз куна.
Саф хисләрне күреп
көнләшкәннәр,
Үч иткәннәр, никтер, күп була.

Карлар хәзер бигрәк көчсез инде
Иртән яуса, кичкә - югала.
Уйнап кына гашыйк булган кебек
Сабырлык та, көч тә юк анда!

Ә мин киләм, куркып кына басып,
Аклыкларын карлар саклар дип.
Чынлап сөйгән гашыйк йөрәгедәй
Үз хисләрен барыбер яклар дип.

*АЛСИНӘ С.*





# Әкияттә кунакта

*Халык иҗаты*



## Кем җиңүче?

Берәүнең өч улы булган Малайлары бер заман өчесе дә үсеп буйга җиткәннәр. Шуннан бу кеше әйткән:

— Улларым, дигән, мин сезне, дигән, өчегезне дә берьюлы өйләндерәм. Сез, минем яныма аерым-аерым кереп, үзегезнең кемне яратуыгыз турында әйтерсез. Мин өчегезгә дә бердән туй ясап, яраткан кызларыгызны алып бирермен, – дигән. Әүвәл олы улын дәшеп керткән:

— Улым, дигән, синең кем кызын аласың килә? – дигән. – Үзең сөйгән кызны алып бирәм, әйт, оялма, – дигән. Малае атасына әйткән:

— Закир абзый кызын алам, – дигән. Анысы чыгып киткәч, этиләре уртанчы улын дәшкән:
— Улым, дигән, мин сине өйләндерәм. Миннән оялма, әйт, кем кызын алып бирим? – дигән.

Бу да:

– Закир абзый кызын алып бир, – дигән. Янә кечесен дәшкән, анысы да шулай әйткән. Ахры, теге кыз бик матур нәрсә булгандыр.

Шуннан бу кеше улларын өчесен берьюлы дәшкән дә әйткән:
– Улларым, Закирның кызы бер генә. Сезнең өчегез дә шуны алырга тели. Бер кызны өчегезгә дә алып булмый. Сез, дигән, өйдә булган хәтле акчаны алыгыз да чыгып китегез. Кайсыгыз кызыклы нәрсә алып кайтыр, Закир кызы шуңа булыр дигән.

– Ярар, – дигәннәр егетләр, атасыннан акча алганнар. Атасы әйткән, чыгып киткәндә: — Берегез дә нәрсә алганыгызны икенчегезгә әйтмәгез, – дигән.

Егетләр чыгып киткәннәр: берсе киткән Энәле ягына, берсе киткән Бураш ягына, берсе киткән Борнаш ягына. Алар киткән, азында өч-дурт мең чакрым җир.

Олы улы, йөри торгач, бик кыйммәтле көзге алган. Икенчесе бик кыйммәтле бәягә палас алган. Кечкенәсе: «Дөньяда моннан да кирәкле бер әйбер дә юк инде», – дип, бер алма алган. Болар кайтканда өчесе дә бер станциягә туры килгән. Вокзалда очрашканнар. Өч туган бер-берсеннән исәнлек-саулык сорашканнар. Шуннан әйбер табу турында да суз чыккан. Олы агалары әйткән:

— Мин көзге алдым, менә карыйк әле, – дигән. Көзгене кесәсеннән алган да, бергә караганнар. Карасалар, Закир абзыйның кызы үлеп ята. Ничәмә мең чакрымнан күренә көзгедән. Олы агалары шул чагында әйткән:

— Беребезгә дә булмый икән, бу үлә икән инде, – дигән. Уртанчылары әйткән:

— Минем паласым бар, сәгатенә өч мең чакрым кайта. Шуңа утырабыз да кайтабыз, – дигән.

Кечкенәләре әйткән:

— Мин алма сатып алдым. Шуны ашаткач, нинди үлә торган кеше дә терелә, – дигән.

Болар, паласка утырып очып, тиз генә кайтып җитәләр. Кыз хәл эчендә ята икән, ди. Баралар да теге алманы ашаталар. Кыз шуннан сикереп тора, элеккедән дә матуррак була. Йә, хәзер кыз кемгә була инде?

# Ел фасыллары турында табышмаклар

Халык иҗаты



Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява.
Җирләр дымлана.
Бу кайчак була?

*(Көз көне)*

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.
Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура,—
Бу кайчак була?

*(Җәй)*



Тәңкә карлар сибелгән
Җир ап-акка күмелгән.
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак?

*(Кыш)*



Йолдыз, йолдыз вак кына,
Яфраклары ак кына.
Өс киемеңә куна,
Тәнгә тисә су була.

*(Кар бөртеге)*



Гәрәбә

Халык

иҗаты

Яңгырлы да карлы
Ә каеннар сулы.
Бөреләр туп-тулы –
Елның кай фасылы?

*(Яз)*



Һәр җир карланган,
Сулар бозланган,
Уйный җил-буран,
Бу кайчак, туган?

*(Кыш көне)*





Өй башына утырган,
Җир йөзен нур белән
тутырган.

*(Кояш)*

# Тәмле торт рецепты

Хуҗабикә

Баллы (медовый) тортның күп төрләләрен ашап караган бар, әмма әлеге рецепт буенча үзем пешергәне барысыннан да тәмлерәк тоела. Сусыл, бик баллы да булмаган туклыклы бу ризык сезгә дә ошар дип уйлыйм.

3 йомыркага 1 стакан (180 г) шикәр комы салып тугларга кирәк. Аерым кечкенә савытта 2 аш кашыгы балга 1 чәй кашыгы сода салып яхшылап болгатасы. Бал ак төскә керергә тиеш. Ике массаны кушып болгаткач, 200 г акмай яки маргаринны эретеп өстисе. 3-3,5 стакан он кушып бик куе булмаган камыр барлыкка килергә тиеш. Әйтергә кирәк: камыр сыек сыман тоелачак, әмма 20-30 минут суыткычта торткач, кулга алып әвәләрлек хәлгә киләчәк. Барлыкка килгән массаны 8-9 өлешкә бүлеп пешерәм. Камырын пешерәсе калайга 3-4 мм калынлыкта, хәтта үтә күренмәле итеп кул белән генә җәям. Тигез пешсен өчен чәнечке белән тишкәләп чыгам. Йөзе килгәнче пешереп аласы. Камырыгыз суыткычта торсын. Коржиклар бераз суынгач, крем буяп, бизәп, суыткычка куегыз. 2-3 сәгатьтән әзер була. Баллырак яратучылар бер-ике катламга берәр төрле джем яки куе кайнатма сала ала.



Тәмле булсын!

# Ак кошлар

Уңган куллар



Гадәттә, без үз йортыбыздагы интерьерны сатып алынган төрле сувенирлар белән бизәргә ияләшкән. Ләкин, теләгең булса, барлык әйберне үз кулларың белән ясарга була. Әйткәнемчә, теләгең генә булсын!

Бу номернын “Уңган куллар” рубрикасында без сезгә бик гади һәм матур кул ясалмасын тәкъдим итәбез.

Оригами - кәгазьдән төрле скульптуралар ясау сәнгате. Оригами сәнгате безгә Япониядән килгән, ә инде бүгенге көндә ул төрле шәһәрләрдә һәм илләрдә кулланыла.

***Кирәкле материал:***


Ак кәгазь

Кайчы


***Эш тәртибе:***

Кәгазне уртага бүләбез һәм озынлыктан кисәбез. Киселгән кәгазьләрне тагын озынлыкка уртага бүләбез. 4 буй килеп чыга. Һәрбер буйны уртага бүләбез һәм аркылыга кисәбез. Һәрбер буйдан 4 турыпочмак ясыйбыз. 1 биттән 16 модуль килеп чыгарга тиеш. Һәрбер модульне бертөрле кушып.

1)



2)




3)



Беренче, икенче һәм өченче рәттә 20 модуль булырга тиеш.

4)




*Уңган куллар*

5)



6)



Дүртенче рәткә модульләрне шулай ук тезәбез.



7)

Бишенче рәт: модульләрне кире яклы итеп тезәбез. Калган рәтләрне шулай ук тезеп чыгабыз (аккошларның биеклеген үзегез сайлыйсыз).

*Уңышлар!*


*Насибуллина Альбина , 212 төркем*

*Тәрәбә*

# Кроссворд

*Башваткыч*






**Горизонталь буенча:** 5. Гелиоцентрик системага нигез салган астроном. 7. Нәрсәгә дә булса уралып үсә торган үсемлек. 9. Рельслар буйлап йөк ташый торган арба. 10. Стена тигезли торган измә. 11. Эт (балалар телендә). 13. Бөтерелеп торган җил баганасы.14. Башкортстандагы район. 18. Юк-бар нәрсәдән әсәренеп яки ярсып китү. 19. Урман куелыгы. 20. Чын нәрсәне алыштыра торган ясалма нәрсә. 22. Нигез салу өчен казылган чокыр. 24. Кыргызстанның башкаласы. 26. Чабышкы ат. 27. Көнбатыш Башкортстандагы зур күл. 31. Тереклекне физика законнарына бәйләп өйрәнә торган фән. 32. Тәмәке савыты. 33. Гәзит-журналларда җитәкче хезмәткәр. 34. Күренекле татар шагыйре Нури ... .

**Вертикаль буенча:** 1. Борынгыдан калган фантастик риваять. 2. Үз-үзең турында белешмә язуы. 3. Эшнең алга бармавы. 4. "Сөбханалла"га кушып әйтелә торган сүз. 5. Көньяк Африкадагы бик коры чүл. 6. Күренекле татар-башкорт җырчысы. 7. Атна көне. 8. Тирә-юньнән биегрәк булып торган урын. 12. Бик эре җир кисәге. 15. Абсолют нульдән башлана торган температура шкаласы берәмлеге. 16. Бурада бер рәт бүрәнәләр. 17. Кыска һәм шаян пьеса. 20. Нарат сумаласыннан ясала торган хуш исле сыекча. 21. Корридада үгез белән көрәшүче. 22. Литвадагы шәһәр. 23. Берәр эшнең чамасын күрсәтә торган саннар, үлчәмнәр. 25. XX гасыр башында иҗат иткән әдип. 28. Татарстандагы район. 29. Җепне каты итеп бөтерү. 30. Алтын чыгара торган урын, предприятие.



Ля-ля-ля

# Ж□□□□□□ ә□□□




Бас, кызым, Әпипә,
Син басмасаң , мин басам.
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам.

Бас, кызым, Әпипә,
Син басмасаң , мин басам.
Әпипәнең калачларын
Ашап калыйм ичмасам.

Бас, кызым,Әпипә,
Идәннәре селкенсен:
Идәннәре селкенсен дә
Кияү куңеле җилкенсен.

Бас, кызым, Әпипә,
Сындыр идән тактасын.
Сындырсаң идән тактасын,
Кияү түләр акчасын.




*<u>Әдәби консультант</u>: “ГӘРӘБӘ” әдәби берләшмәсе җитәкчесе Нуриева Лилия Фаил кызы*

*<u>Баш мөхәррир</u>:Мәрдәнова Айгөл*

*<u>Редколлегия</u>: “ГӘРӘБӘ” әдәби берләшмәсе әгъзалары*

